**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ГОРОДА ЛАИШЕВО**

ул. Коммунальная,
д.3,г.Лаишево,422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘРЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Коммунальная ур., 3 нче йорт,
Лаеш ш.,422610

тел: 8-(84378) -2-57-77, факс: 8-(84378) -2-50-62, e-mail:Gorod.La@tatar.ru

**2021 елның 11мае** **163 номер**

# КАРАР

**Җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне тәэмин итү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында һәм «Инком Холдинг» ҖЧҖ директоры А.Н. Гобәйдуллин гаризасы нигезендә карар бирәм**:**

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, Лебедева ур., адресы буенча урнашкан 16:24:170127:17кадастр номеры белән, «административ биналар урнаштыру өчен», «кибетләр - товарлар сату өчен билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен»» белән, шартлы рәвештә рөхсәт ителгән җир кишәрлегеннән файдалану төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссия 2021 елның 14 июнендә 13 сәгать 00 минутта- ТР, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, Коммунальная ур., 3 йорт адресы буенча урнашкан Лаеш шәһәре Башкарма комитеты бинасында ачык тыңлаулар үткәрергә.

3. Ачык тыңлауларга чыгарыла торган сорау буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе секретаре тарафыннан түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы Лаеш районы, Лаеш шәһәре, Коммуналь ур., 3 йорт, тел.: (84378)2-57-77.

4. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Лаеш шәһәре Башкарма
комитеты җитәкчесе В.А. Арефьев